| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ЭБАЛАКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯБАЛАК АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 нчы октябрь 2020 ел Ябалак авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының Кече Кайбыч авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 маддәләре,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Уставының 22маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 10 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кече Кайбыч авылы,Мәктәп урамы,10А адресы буенча урнашкан башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Кече Кайбыч авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә.

2. 2020 елның 11ноябренә 11 сәгать 00 минутка Кече Кайбыч авылы,Үзәк урамы,52 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Кече Кайбыч авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.

3 2020 елның 11 нояберенә 13 сәгать 00 минутка Кече Кайбыч авылы, Үзәк урамы, 2 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Кече Кайбыч авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын** билгеләргә.

4. 2020 елның 12 нояберенә 14 сәгать 00 минутка Кече Кайбыч авылы, Урман урамы,4 нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Кече Кайбыч авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын** билгеләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Ябалак авыл җирлеге Кече Кайбыч авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- җирлектәге торак пунктлардагы чүплекләрне чистарту;
- материаллар сатып алып чишмәне төзекләндерү;
- материаллар сатып алып су челтәрләрен ремонтлау;
- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре (Гигиена һәм эпидемиология үзәге федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесендә суны анализлау, "Санитар саклау зоналары" һәм "Эчәр су" зоналарында СанПин нормаларына экспертиза үткәрү, санитар-эпидемиология нәтиҗәсе алу);
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- материаллар сатып алып«Изгеләр» зиратын чистарту һәм ремонтлау».

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районы

Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф